**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№772**
**05.02.2021**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешнең 23 пункты, «Күмү һәм җирләү эшләре турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясының 3 өлеше, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2021 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрнең коэффициентын раслау турында» 2021 елның 28 гыйнварындагы 73 номерлы Карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Күмү һәм җирләү эшләре турында» Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен кушымталарда каралганча 6 424,98 сум күләмендә расларга һәм 2021 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» 2020 елның 7 февралендәге 544 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы И.Н. Гайнуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 5 февралендәге
772 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә
җирләү буенча гарантияләнгән
хезмәтләр исемлегенә бәяләр
(якын туганнары, ире (хатыны) булган очракта)

| Хезмәтләрнең исеме | Хезмәтләрнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китереп бирү | 1800,00 |
| 3. Үлгән кешене (мәетне) зиратка илтү | 890,00 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3734,98 |
| Барлыгы | 6424,98 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2021 елның 5 февралендәге
772 номерлы карарына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә
җирләү буенча гарантияләнгән
хезмәтләр исемлегенә бәяләр
(якын туганнары, законлы вәкиле булмаган очракта)

| Хезмәтләрнең исеме | Хезмәтләрнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Мәетне төрү | 691,47 |
| 3. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китереп бирү | 1108,65 |
| 4. Үлгән кешене (мәетне) зиратка илтү | 890,00 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3734,86 |
| Барлыгы | 6424,98 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева